Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Күн авыл жирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

6 май 2020 ел № 3

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү өчен автомобиль юлы төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатыннан чыгып, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү өчен автомобиль юлы төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм межалау проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге уставы, Күн авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 63 номерлы карары (13.12.2017 ел, № 78, 25.05.2018 ел, № 90, 20.09.2009 ел, № 133 үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлегендә гавами тынлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә белән **карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү өчен автомобиль юлы төзү» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 10.06.2020 - 10.00;

2.2. үткәрү вакыты - 1 көн;

2.3. үткәрү урыны - Күн авылы мәдәният йорты, Күн авылы, Совет урамы, 61а;

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Күн алы, Совет ур., 61а йорт, авыл мәдәният йорты чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен бирелә;

2.5. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 09.06.2020;

- язмача, эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Күн авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: Күн авылы, Совет урамы, 61а йорт, гражданнар өчен мәҗбүри күрсәтелгән: фамилия, исем, әтисенең исеме, яшәү урыны, эш урыны һәм биләгән вазыйфасы, элемтә өчен телефоннар: бер төркем гражданнар – фамилияләре, исемнәре, атасының исеемнәре, нинди дә булса иҗтимагый оешмаларга яки берләшмәләргә

караву (булган очракта), яшәү урынын теркәү адреслары, элемтә өчен телефоннар, юридик затлар өчен - оешма бланкында, җитәкченең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтеп.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү өчен автомобиль юлы төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. 09.05.202020 елга кадәр әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов